РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» март 2025г. г. Альметьевск №346

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының Закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 131 статьясындагы 2 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 һәм 19 статьялары нигезендә «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында», Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы белән

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яңа Никольский авыл җирлегенең Хазовка поселогын бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Бута урманчылыгын бетерергә.

3. «Татарстан Республикасы Әлмәт районының аерым авыл торак пунктларын бетерү һәм «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында «Татарстан Республикасы Әлмәт районының аерым авыл торак пунктларын бетерү һәм «Әлмәт муниципаль районы «муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын караганда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы вәкиле итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары Әфләтунова Роза Егор кызын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Муниципаль район башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Е. Әфләтунова